СОВЕТ КАРАДУВАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАРАДУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
«30» сентябрь 2019 ел.

**КАРАР**
№115

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге 2018 елның 23 ноябрендә кабул ителгән 91 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы " Карадуган авыл җирлеге "муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында" карарына үзгәрешләр кертү турында"

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның үзгәрүе сәбәпле, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының « Карадуган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Карадуган авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге 2018 елның 23 ноябрендә кабул ителгән 91 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы " Карадуган авыл җирлеге "муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында" карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә :

- 1.6 пунктның 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

җирлекара территориядә урнашкан торак пунктта, яңа оешкан җирлек булдыру турында халык инициативасын тәкъдим итү максатларында, шулай ук яңа оешкан җирлектә, әгәр сайлау хокукына ия кешеләр саны 300 дән артмаган булса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча";

- 3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Әлеге статьяда каралган гражданнар җыены анда торак пункт яки җирлек халкының сайлау хокукына ия булган яртысыннан артыгы катнашуга хокуклы. Торак пунктта сайлау хокукына ия кешеләрнең яртысыннан артыгы бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаса, күрсәтелгән торак пункт кергән муниципаль берәмлек уставы нигезендә гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгән көннән бер айдан да артык булмаган вакытка этаплап уздырыла. Шул ук вакытта, элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә киләсе этапларда катнашмый. Әгәр дә җыенда катнашучыларның яртысыннан артыгы аның өчен тавыш бирсәләр, гражданнар җыены карары кабул ителгән дип санала ";

2. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми сайтында, baltasi.tatarstan.ru интернет челтәрендә һәм http: //pravo .tatarstan. ru/. Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Рәсми басылып чыккан вакыттан карар үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач муниципаль районы
Карадуган авыл җирлеге башлыгы: Ш.В.Низамиев